РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Школьная ул., д. 1, с. Алан, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Алан авылы, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053621 ОГРН 1061675010176 ИНН/КПП 1619004387/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№8/1** **« 19» апрель 2022 ел**

**Телче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитетының 09.03.2022 ел №5 «2022 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясенең Хөкүмәте «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1.Телче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитетының 09.03.2022 ел №5 «2022 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» карарының 1 пунктына түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә: «1.1 номерлы кушымта һәм 2 номерлы кушымта нигезендә Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү һәм гамәлгә кертү.

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Алан авыл
җирлеге Башкарма

комитетының «09» март 2022 ел
№ 5  1 номерлы кушымта

2022 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 135,50 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2900,14 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 828,72 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3100,32 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **6964,98** |

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Алан авыл
җирлеге Башкарма
комитетының «09» март 2022 ел
№ 5  2 номерлы кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 135,50 |
| 2. Кәфенләү | 250,61 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү. | 2649,53 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 828,72 |

| | |
|---|---|
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3100,32 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **6964,98** |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 1 февраленнн барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Теләче муниципаль районы
Алан авыл җирлеге башлыгы Б.Н. Хәсәнов